ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 7 17 гыйнвар 2019 ел

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәренең яшел утыртмаларын карап тоту чаралары турында» 2007 елның 11 маендагы 12 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.22. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.22. Агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау, саклау яисә утырту өчен карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (22-нче кушымта).».

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау, саклау яисә утырту өчен рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган

үзгәрешләрне (22-нче кушымта) расларга.

3. Җәмәгатьчелек һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 17-нче гыйнвар
7-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маендагы 804 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау, саклау яисә утырту өчен карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр (22-нче кушымта).

1. 1 бүлектәге 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яисә утыртуга карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).».

2. 1.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне үтәү хезмәт һәм әйләнә-тирә мохитне саклау бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар кабул итүне Башкарма комитет гамәлгә ашыра».

3. 1.3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.1 Башкарма комитетның урнашу урыны: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12-нче йорт.

Эш графигы:
дүшәмбе - җомга: 8.00-17.00;
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты:12.00-13.00
Белешмә телефоны: 42-50-50.
Узу шәхесне раслаучы документлар буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, Башкарма комитетның хезмәтне һәм әйләнә – тирә мохитне саклау бүлеге белгече консультация, документлар әзерләү һәм бирүне гамәлгә ашыра (алга таба – Бүлек).

Бүлекнең урнашу урыны: Түбән Кама шәһәре, Мәктәп бульвары, 2а йорт, 223 кабинет.

Эш графигы:
дүшәмбе - җомга: 8.00-17.00;
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты:12.00-13.00
Белешмә телефоны: 42-43-96, 42-48-11».

4. 1.3.2. пунктының 3) пунктчасындагы «(http://uslugi. tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi. tatarstan.ru/)» сүзләренә алмаштырырга.

5. 1.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

кисү – тиешле җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә агачлар һәм куаклар тулысынча яки өлешчә киселә торган агач һәм куакларны кисү;

ябалдаш ясау – декоратив һәм гамәли максатларда, агач һәм куак ботакларын декоратив һәм яшәртү өчен кисү;

утырту – тиешле җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә агач һәм куакларны туфракка, грунтка утырту процессы;

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату (27.07.2010, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 пункты). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк буенча яки стандарт бланкта (2нче кушымта) ирекле формада тутырыла;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (27.07.2010, № 210-ФЗ Федераль законның 2 ст 2 пункты). Гариза стандарт бланкта (2-нче кушымта) тутырыла.».

6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яки утыртуга карар бирү».

7. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яки утыртуга карар (1-нче кушымта)».

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яки утыртуга рөхсәт бирмәү турында хәбәрнамә» сүзләрен «агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яки утыртуга карар» сүзләренә алмаштырырга.

8. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга, саклауга яки утыртуга карар, гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә бирелә.».

9. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Гариза (2-нче кушымта);

2) Шәхесне раслаучы документлар;

3) Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эшләсә);

4) Якындагы корылмаларга яки киселергә тиешле яшел утыртмалар төшерелгән башка ориентирларга кадәр кишәрлек схемасы;

5) Әгәр җир кишәрлеге Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки хокукны раслаучы документларның расланган күчермәләре;

6) Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмалар киселгән очракта, расланган проект документлары;

7) Территорияләргә кагылучы яшел утыртмаларны кисү һәм аларны күчереп утырту шартларын кагылышлы территория хуҗалары белән килештерү;

8) Яшел үтыртмалар утыртканда һәм күчереп утыртканда җир эшләрен үткәрүгә ордер ачу белән инженерлык челтәрләре вәкилләре белән килештерү.».

10. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында барлыкка килә:

Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган).

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.».

11. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы булмаган күләмдә бирелгән, я тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

2) Әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында таныклаучы ведомствоара соратуга дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимиятенең ведомство карамагындагы органының яисә оешманың җирле үзидарә органының җавабы керү;

3) Күрше җир биләмәләреннән файдаланучылар арасында агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау, саклау яки утырту мәсьәләсе буенча бәхәс булу.».

12. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.11. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмалар һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү бәясен исәпләү методикасы белән билгеләнә.»

13. «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт» баганасының 2.11. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты Җитәкчесенең 2008 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары.».

14. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.12. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чират булган очракта муниципаль хезмәт күрсәтү алу өчен гариза бирү – 15 минуттан да артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алган вакытта чиратны максималь көтү срогы 30 минуттан артмаска тиеш.».

15. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.13. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.».

16. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр.».

17. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын системасы һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

18. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бина җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүе алучы инвалидларга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм күрсәтү.».

19. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.16. пунктында «(http://uslugi. tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi. tatarstan.ru/)» сүзләренә алмаштырырга.

20. Дүртенче абзацның 3.1.1. пунктчасын «комиссия» сүзләреннән соң «яшел утыртмаларны тартып алуны килештерү буенча» сүзләре белән тулыландырырга.

21. 3.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.1.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1.2. «Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр блок-схемасы 4-нче кушымтада күрсәтелгән.».

22. 3.2.1. пунктчасының икенче абзацын «хезмәтләр күрсәтү» сүзләреннән соң «кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә» сүзләре белән тулыландырырга.

23. 3.3.1. пунктчасының беренче абзацында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитетның эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

24. 3.3.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. «Гаризалар кабул итүне алып баручы Башкарма комитетның эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү (Ышаныч кәгазе белән эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;

тәкъдим ителгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартулар, өстәп язулар, сызган сүзләр һәм башка сөйләшенмәгән төзәтүләр булмау).

Искәрмәләр булмаган очракта Башкарма комитетның эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге белгече гамәлгә ашыра:

гаризаларны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүне үтәү датасы һәм вакыты турында тамга белән тапшырылган документларның күчермәләре исемлеген тапшыру;

Башкарма комитет Җитәкчесенә карап тикшерү өчен гаризаны җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризалар һәм документлар кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны гариза кергән вакыттан бер көн эчендә теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.».

25. 3.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Яшел утыртмаларны алуны килештерү буенча комиссия актын төзү.

3.5.1. Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

тапшырылган документларда булган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү;

хисап эшен рәсмиләштерү (барлык документларны аерым папкага туплау);

хисап эшен акт төзү өчен комиссия каравына юнәлдерү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җаваплар кергән вакыттан алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.».

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссиягә җибәрелгән хисап эше.

3.5.2. Комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

кабул ителгән документларны өйрәнү;

киселергә, ябалдаш ясалырга, сакларга тиешле агачларның яки куакларның урнашу урыннарын, яки утырту урыннарын карау датасын билгеләү;

комиссия әгъзаларына һәм мөрәҗәгать итүчегә карау датасы турында хәбәр итү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документлар кергән вакыттан алып ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына һәм мөрәҗәгать итүчегә карау датасы турында хәбәр итү».

26. 3.5.3. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән көнне яшел утыртмаларны алуны килештерү комиссиясе урынга чыга һәм мөрәҗәгать итүче катнашында киселергә, ябалдаш ясалырга, сакларга тиешле агачларны һәм куакларны карауны гамәлгә ашыра.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү һәм Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмалар бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү уздыру акты (3нче кушымта) төзелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар агач һәм куакларның урнашу урыннарын карау көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: яшел үсентеләрне алуны килештерү буенча комиссия секретаре тарафыннан әзерләнгән һәм яшел үсентеләрне алуны килештерү

буенча комиссия әгъзалары тарафыннан килештерелгән тикшерү һәм Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерүне үткәрү (торгызу бәясе акчалата формада алына торган очракта) акты.».

27. 3.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгече яшел утыртмаларны алуны килештерү буенча комиссия әгъзалары тарафыннан килештерелгән тикшерү һәм Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмалар бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү акты нигезендә (әгәр яңадан торгызу бәясе акчалата формада алына икән), агач һәм куакларны кисүгә, ябалдаш ясауга яки утыртуга, карап тотуга карар проекты яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә проекты (алга таба – хәбәрнамә) әзерли һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Түбән Кама шәһәре территориясендә тикшерү, алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмалар бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү акты (әгәр яңадан торгызу бәясе акчалата формада алына икән) керү вакытыннан ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалауга җибәрелгән яшел үсентеләрне алу турында карар проекты (хәбәрнамә).».

3.6.2. Башкарма комитет Җитәкчесе агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау яки утырту, карап тоту турында карарны имзалый һәм Башкарма комитетның эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегендә теркәлгәннән соң гариза бирүчегә тапшыру өчен Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау яки утырту, карап тоту турында имзаланган һәм теркәлгән Бүлек белгеченә җибәрелгән карар».

28. 3.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау яки утырту, карап тоту турында карарны бирә яисә почта аша җибәрә.

Агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау яки утырту, саклауга карар белән бергә мөрәҗәгать итүчегә Түбән Кама шәһәре территориясендә тикшерү, алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмалар бәясен исәпләү һәм компенсацион яшелләндерү үткәрү акты (әгәр яңадан торгызу бәясе акчалата формада алына икән) тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә – мөрәҗәгать итүченең шәхси килүе очрагында;

алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә – почта аша җавап җибәргән очракта.

Процедураның нәтиҗәсе: Агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау яки утырту, карап тотуга бирелгән (җибәрелгән) карар, почта аша хат җибәрү турында хәбәрнамә.».

29. 3.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

- техник хаталарны төзәтү турында гариза (5-нче кушымта);

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;

- техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Идарә белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6. пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның оригиналын мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтелгән документны имзалатып шәхсән бирә, яки мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта аша) Бүлеккә техник хата булган документның оригиналын тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хаталар ачыклангannнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң 7 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.».

30. 4.2. пункты «Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

31. 4.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплылык тота.

Бүлек башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык тота.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.».

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлеге ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла».

32. Регламентка 1-нче кушымтаны теркәлгән яңа редакциядә бәян итәргә.

33. Регламентны 5-нче кушымта белән теркәлгән редакциядә тулыландырырга.

1-нче кушымта

№_____ 201_ елның «___» __________

Агач һәм куакларны кисү, ябалдаш ясау, саклау яки утыртуга
_____номерлы карар

Бирелгән: ________________________________________(вазыйфа, Ф.И.О.)
Адрес: ________________________________________________________
Нигез: _____________гариза (Ф.И.О., вазыйфа), чыгу номеры, датасы, керү номеры, датасы.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау Кагыйдәләренең 10 ст. 6 пункты нигезендә (Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 27 декабрендәге 32нче номерлы һәм үзгәртүләр һәм өстәмәләр

белән 2007 елның 23 октябрендәге карары белән расланган),_____елның____ __________ ____номерлы тикшерү актына таянып, ________________________________________________________________________ ________________________________________________________________________

адресы буенча рөхсәт бирергә.

Утыртмаларны алу шартлары: ________________________________________________________________________ ________________________________________________________________________

Агачларны алып ташлау куркынычсызлык техникасы нигезендә башкарыла. Әгәр Россия Федерациясендә гамәлдә булган кагыйдәләр (таләпләр, техник шартлар) нигезендә аерым агач яки куаклыкларны (билгеләнгән территорияләрдән агач яки куаклар) кисү махсус оешмалар (белгечләр) яки махсус җиһазлар җәлеп итеп гамәлгә ашырыла икән, мөрәҗәгать итүче әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

Агач һәм куакларны кисү эшләрен башкарганнан соң территорияне гомуми төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру (агач кәүсәләрен, ботакларны, башка чүп-чар чыгаруны да кертеп) мәҗбүри булып тора.

Карарның гамәлдә булу срогы: ___________________________

Әлеге карарның шартларын үтәү өчен җаваплы:__________(Ф.И.О., вазыйфа)

5-нче кушымта

Татарстан Республикасы
_________________муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенә
__________________________________нан

техник хатаны төзәтү турында
гариза.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
_____________________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:____________ __________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_______ ____________________________________________
_____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:________

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча:
_____________________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм:___________ _________.

______________ ________________ (________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)